ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 106-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 106-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 401-VII ДС

106-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, №1; 2010, №5 ( I өлеш); 2011, №6 (I өлеш), №10 (I өлеш )); 2012, №1; 2013, №1; 2014, №5, №6 (II өлеш), №7; 2015, №4; 2016, №1 - 2, №5; Татарстан Республикасы законнар җыентыгы, 2016, №40 (I өлеш), №44 (I өлеш); 2017, №27 (I өлеш); 2018, №54 (I өлеш); 2019, №2 (I өлеш), №19 (I өлеш); 2020, №4 (I өлеш), №37 (I өлеш), №57 (I өлеш), №77 (I өлеш); 2021, №20 (I өлеш), №57 (I өлеш), №93 (I өлеш); 2022, №34 (I өлеш), №57 (I өлеш), №83 (I өлеш); 2023, №27 (I өлеш), №35 (I өлеш), №48 (I өлеш), №56 (I өлеш), №81 (I өлеш); 2024, №86 (I өлеш); 2024, №16 (I өлеш), №16 (I өлеш), №47 (I өлеш); 2025, №18 (I өлеш) үзгәреш кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«45 статья. Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге)**

1. Региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү (зыян салу) яисә зарар китерү (зыян салу) куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне әзерләнә торган бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин.

3. Күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) органы тарафыннан

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин.».

**2 статья**

«Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2022 елның 25 февралендәге 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Республикасы законнар җыентыгы, 2022, №17 (I өлеш), №77 (I өлеш); 2023, №73 (I өлеш); 2024, №76 (I өлеш)) үзгәреш кертеп, аңа түбәндәге эчтәлекле 5 һәм 6 өлешләр өстәргә:

«5. Мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү (зыян салу) яисә зарар китерү (зыян салу) куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне әзерләнә торган бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин.

6. Күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, Татарстан Республикасы җир асты байлыкларының дәүләт фонды белән идарә итү органы тарафыннан «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) региональ дәүләт контроле (күзәтчелеге) өлкәсендә федераль законнарга кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә эшләнде.

2025 елның 1 гыйнварыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 11 сентябрендәге 1234 номерлы карары үз көченә керде, карар белән расланган Үзгәрешләрнең 3 пунктына ярашлы рәвештә, контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлектән башка контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрү нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр бирү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законда һәм әлеге карарда каралган очракларда рөхсәт ителә.

Шул ук вакытта әлеге карар үз көченә кергәнчегә кадәр контрольдә тотылучы зат белән үзара хезмәттәшлектән башка контрольлек (күзәтчелек) чараларын уздыру нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру үзенчәлекләре турында» 2022 елның 10 мартындагы 336 номерлы карарының $7^2$ пункты белән тыелган иде.

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба — 248-ФЗ номерлы Федераль закон) 74 статьясы нигезендә, әгәр мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) барышында закон белән саклана торган кыйммәтләргә зарар китерү (зыян салу) яки зарар китерү (зыян салу) куркынычы барлыкка килү фактлары, мәҗбүри таләпләрне бозулар турында, мәҗбүри таләпләрне әзерләнә торган бозулар яисә мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре турында белешмәләр ачыкланса, контрольлек төре турында федераль законда, Россия Федерациясе субъектының контрольлек төре турындагы законында мондый мөмкинлек күрсәтелгән очракта, контрольлек (күзәтчелек) органы әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү хакында карар кабул итәргә мөмкин.

248-ФЗ номерлы Федераль законның 75 статьясында каралганча, күчмә тикшерү кысаларында мәҗбүри таләпләрне бозу билгеләре ачыкланса, контрольлек төре турында федераль законда, контрольлек төре турында Россия Федерациясе субъекты законында мондый мөмкинлек күрсәтелгән очракта, әлеге Федераль законның 90 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган тәртиптә ачыкланган

хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул ителергә мөмкин.

Бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, закон проектында мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү (куркынычсызлык мониторингы) нәтиҗәләре буенча да, шулай ук күчмә тикшерү нәтиҗәләре буенча да контрольлек төрләре турында республиканың аерым закон актларында контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирү турында карар кабул итү мөмкинлеген беркетү тәкъдим ителә.

Проектка карата җайга салу йогынтысын бәяләү процедурасы үткәрелде (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2025 елның 7 маендагы 01-53/3179 номерлы бәяләмәсе).

Проект коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру һәм иҗтимагый фикер алышу максатларында норматив хокукый актлар проектларын урнаштыру өчен мәгълүмат ресурсында урнаштырылган иде (http://tatarstan.ru/regulation). Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр килмәде.

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы закон актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмә раслау хакында» 2021 елның 22 сентябрендәге 895 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә региональ дәүләт экология контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәгә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 30 сентябрендәге 940 номерлы карары белән расланган Региональ дәүләт геологик контроле (күзәтчелеге) турында нигезләмәгә, проектта тәкъдим ителә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, контрольлектәге зат белән үзара хезмәттәшлектән башка контрольлек (күзәтчелек) чараларын үткәрү тәртибен төгәлләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү таләп ителәчәк.

**«Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Экология кодексының 45 статьясына һәм «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми һәм аның керем өлешенә йогынты ясамый.